# REVIEW OF THE BOOK "THE SIBERIAN TATARS" BY F. YU. YUSUPOV. FROM THE SPIRITUAL CULTURAL TREASURY. ANTHOLOGY OF THE SIBERIAN TATARS' FOLKLORE: DASTANS, MUNADGATS, BAYTS. KAZAN: KAZAN UNIVERSITY PUBLISHING HOUSE, 2014. 648 p."

**Fanzilya Khakimovna Zavgarova,**
"The Republican Centre for Traditional Cultural Development" State Institution,
66/33 Pushkin Str., Kazan, 420015, Russian Federation,
zavgarova@inbox.ru.

**Gafur Masgutovich Sungatov,**
"The Republican Centre for Traditional Cultural Development" State Institution,
66/33 Pushkin Str., Kazan, 420015, Russian Federation,
gsungatov@mail.ru.

The book "The Siberian Tatars. From the Spiritual Cultural Treasury. Anthology of the Siberian Tatars' Folklore: Dastans, Munadgats, Bayts. Kazan: Kazan University Publishing House, 2014. 648 p." by Prof. F. Yu. Yusupov, D. Litt., Corresponding Member of the Turkish Linguistic Society, includes dastans, munadgats and bayts that were recorded in the $19^{th}$-$20^{th}$ centuries. Continuing the tradition of the great researcher and scholar V. V. Radlov, the author accompanies these folklore pieces with transcription, reflecting the local pronunciation.

Speaking of munandgats and bayts, recorded by the author himself, F. Yu.Yusupov points out their consonance with folklore pieces of other Tatar ethnic groups, whereas dastans, surviving only among the Siberian Tatars, have similarities with the same genre of other Turkic peoples. The book presents data, stating that, in terms of their content and form, these dastans can be traced back to ancient Orkhon Turkic written monuments. The book would appeal to a wide range of readers due to the line-by-line translation of these literary gems to Russian, its new research information on the history of the Siberian Tatars and on the features of each of the genres.

**Key words**: oral lore, spiritual cultural monuments, folklore text, dastans, munadgats, bayt.

The further the human society develops, the greater is the people's interest in their spiritual and cultural values. The study of folklore, ancient national traditions, customs and rituals is one of the most relevant issues in European cultural institutions. As the spiritual culture of many European peoples is under threat of disappearance, one of the most important goals in this field is to revive ethnic traditions, if it is still possible. From this point of view, our situation is similar to the European one – some of the genres of Tatar oral lore are dying out. Thus, many dastans about our heroes, historical figures who fought for our integrity, independence, and displayed great courage, or dastans about two hearts and their pure passionate love for each other, those stories people would spend nights telling each other are gone. A few generations have passed without even noticing their disappearance, which has completely changed our life and crippled our spiritual culture. Presumably, a couple of centuries ago, our fathers could not imagine that this spiritual treasure of our nation that once used to leave people in awe could be thrown away like rubbish.

Having foreseen this tragedy and experienced it first hand, European scholars took matters into their own hands and, in order to save one of the most culturally extensive nations of the Russian Empire, tried to preserve as many examples of its spiritual culture as possible. One of these prominent figures was Friedrich Wilhelm Radloff (Vasily Vasilievich Radlov). V. V.Radlov was born in 1837 in Berlin, Germany. Right from the early age, he was very hard-working and talented. Having successfully finished a gymnasium in 1854, he enrolled in Berlin University, the Faculty of Philosophy. At that time, such faculties provided language, history, and anthropology lessons as well. The lectures of August Pott, a founder of the historical comparative approach in linguistics, famous for his works on the origins of various languages, influenced Friedrich's choice of profession. However, his interest in oriental languages and his great contribution to the Ural-Altai theory was conditioned by his close connec-

tion with Wilhelm Schott. These famous scholars' stories about the fascinating secrets of linguistics drove the young man to dedicate his entire life to the language and history of the Turkic people, particularly the Siberian Tatars, living in the Asian part of Russia. Having finished the worldwide famous Berlin University, Friedrich arrived in Saint-Petersburg in 1858 with a letter from Otto von Böhtlingkad dressed to W. Schott with the request to help his student. His biggest dream was to visit the Tatars living in Eastern Siberia, who had never been studied by anyone before, and to start researching their history, language and traditions. Since the Russian government did not allow foreigners to this part of the country, the young scholar had no other choice but to give up his German citizenship and get a Russian passport in order to fulfil this dream. From that moment Friedrich Wilhelm became a Russian citizen and took the name of Vasily Vasilievich. The Russian community was confused and amazed by such determination of the young man. After that, in less than three days, the road to Siberia was finally opened up for the young scholar, and Vasily who was used to the warm European climate started his trip to Barnaulunderclad, on a horse-drawn sledge.

In winter, V. V. Radlov spent his time in the Barnaul Training College (modern polytechnic institute-type higher education establishment), where he taught German and Latin, and organized scientific expeditions to Tatar and other people's settlements in summer. V. V. Radlov published a book called "Examples of Folk Literature of Turkic Tribes from South Siberia and Dzungar Steppe. Part IV. Dialects of Baraba, Tara, Tobol and Tyumen Tatars" (Saint Petersburg, 1872) [Radlov, 1972], based on the materials that he had gathered. This work is considered an origin of the Russian School of Turkic Studies, particularly, Tatar Folklore Studies. The book included Siberian Tatar fairytales, 29 songs, consisting of 680 lines, legends and dastans, which came to 121 pieces in total. On the anniversary of the scholar's 175$^{th}$ birthday, F. Yu. Yusupov, of Kazan Federal University, published this book in 2012 in Kazan [Radlov, 2012].

Unfortunately, it was the only work by V. V. Radlov based on the said principles, or containing folklore pieces of the Siberian Tatars written in the local dialect with transcription. Other than the praise expressed for the turkologist in one or two sentences, which are repeated from article to article, his great and profound work was never truly appreciated, and no full article about his accomplishments has ever been published. At last, recent years have been showing some progress in this field: Professor F. Yu. Yusupov from Kazan Federal University has published more than ten scientific manuscripts on the scholar's life and scientific work and appeared in several international symposia in Russia and abroad. Another work worth mentioning is L. Zakirova monograph, which systematically and comprehensively covers the period when V. V. Radlov lived and worked in Kazan [Zakirova, 2013].

In recent years, with the development of international communication and a blurring of the distinction between peoples and their traditions, the importance increases to learn and compare their spiritual values, ancient traditions, customs, beliefs, and ideals. It is the focus of research for Tatar scholars and researchers of other Turkic nationalities. The book by Prof. F. Yu. Yusupov, D. Litt., Corresponding Member of the Turkish Linguistic Society, called "The Siberian Tatars. From the Spiritual Cultural Treasury. Anthology of the Siberian Tatar Folklore: Dastans, Munadgats, Bayts" is one of such significant works [Yusupov, 2014].

F. Yu. Yusupov dedicated over fifty years of his life to the studies of the Siberian Tatar language and traditions. This experienced scholar has his own explanation as to why these monuments can still be found. When travelling with an expedition to a certain locality, he set his focus on the process of gathering materials. Notably, to study a language, it is crucial to gather and record all the ancient stories, all types of folklore and ethnographic information. The book that this paper focuses on is a result of hard and thorough work aimed at gathering spiritual monuments of our people, the scholar's life work. Some researchers claim that currently there is nothing left to gather from among the people, everything was gathered long ago from the past generations, modern Tatars know nothing. These scholars should learn more about the time when F. Yu. Yusupov compiled his materials: a part of munadgats and bayts were compiled in the 1980s, and others in the 2010s. Thus, in many regions, the connection between generations is still strong and is renewed thanks to the hard work of certain devoted individuals and their love towards the heritage of their fathers.

As the name of the book suggests, it is dedicated to the lyric-epic genres of Siberian Tatar folklore, specifically, dastans, munadgats, and bayts. Judging by the content and structure of this book, based on many years of experience, we can saythat it has made a great contribution to the world and Turkic linguistics layinga new scientific

foundation. Firstly, it is important to remember that this book is the first anthology of Siberian Tatar folklore. Moreover, it filled the blank spot in this field, as there has never been a separate anthology exploring the folklore of any of the three main Tatar ethnic groups – the Kazan Tatars, Mishars, or Siberian Tatars. Another distinguishing feature of this work is the fact that the folklore texts are given with transcription, reflecting the dialect of the Siberian Tatars like in V. V. Radlov's book. Future works of this type should definitely take into consideration this approach. Many scholars in the field of Turkic Folklore Studies never translated folklore texts into the Tatar literary language. The book contains the Russian academic transcription used by such prominent turkologists as V. V. Radlov, N. F. Katanov, D. G. Tumasheva, L. V. Dmitrieva and others, which is well-known to contemporary researchers. This standard type of transcription makes the texts a lot easier to read, in the way they were written down preserving the dialectal pronunciation of each word. Although the texts are translated line by line, they still sound beautiful in Russian as well. Evidently, this effect was achieved owing to the author's profound knowledge of the Siberian Tatar dialects.

A good portion of the book is dedicated to the origin and history of Siberian Tatars. The author considers the Siberian Tatars to be one of the main ethnic groups which formed the Tatar nation and points out their connection to ancient Turkic tribes who lived at East Siberian latitudes before the common era as well as to such peoples as the Xiongnu, Kipchaks, etc. who emerged in this region in the 1$^{st}$ millennium. Besides, for many centuries, the Siberian Tatars were in close relation to the Bolgars who came from the Volga-Ural region, the neighbouring Bashkirs, Kazakhs and Nogais. Their formation was also greatly influenced by the Kazan Tatars who moved to the east after the fall of the Kazan Khanate. F. Yu. Yusupov writes about the Kazan Tatars who arrived from the Volga-Ural region and founded new villages, or settled in the existing ones along with the Siberian Tatars. Naturally, they quickly found common ground not only thanks to the common language they spoke, but also the religion they shared. Islam, as F. Yu. Yusupov's book shows, was introduced way back by the Bolgars. Moreover, it was spread by Muslim missionaries invited by Siberian khans from Central Asia. The book substantiates this information providing numerous historical, ethnographic, and cultures sources. The Tatars from historically kindred tribes managed to form a sovereign state in the Tobolsk-Irtysh lands. However, after it had been conquered by Russia, they were subjected to national and religious discrimination and persecution for many centuries. Their remoteness from the Volga Tatars decreased the influence of the Tatar literary language (it was excluded from school curricular in the 1960s). This and the scatter of the Siberian Tatars over a large territory were the factors that really hindered the cultural development of our fellow brothers. Nevertheless, as the author points out, just like the Volga Tatars, the Siberian Tatars possessed developed stock raising and agricultural systems, they also worked on metal production.

The introduction to the book, called "Siberian Tatars", is written in close to popular scientific language understandable to a wide range of readers, without using obscure special terms. This shows that this major book is aimed at both scholars and people, working in the fields of culture, education, and information, generally, at anyone interested in the spiritual heritage of the Tatar people. This work also includes information about the main phonetic and grammatical features of the Siberian Tatar dialects. F. Yu. Yusupov analyzes the Siberian Tatar dialects from the dialect language perspective in line with other Tatar dialects giving coverage to its phonetic features and morphological system. The author also covers the main classification features of the Tatar dialect that are common to all the areas where the Siberian Tatars live, setting it apart from all other Central and Eastern dialects of the Tatar language. He points out the similarity of the Siberian dialects with the Central ones and compares them to the Mishar dialect. For instance, the Siberian Tatar phonetic system features a common use of **й [j], ц [tz]**, peculiar pronunciation of the sound **ч [ch]** and more open pronunciation of **a,** which makes it similar to Mishar dialect and distinguishes it from the Central dialect; however, such classification features as hard consonants **ķ, ғ** and the use of full labial harmony in the Central and Eastern dialects distinguish it from the Western dialect, etc.

Here it would be appropriate to elaborate on the writing and lecturing style of Farit Yusupov, who dedicated his entire life to studying the language and spiritual monuments of the Tatar people and passing on this knowledge to younger generations. Be it a speech at an academic conference, a lecture, any statement on one of the issues during a meeting or an academic paper, he always uses popular terms easily understood by his audience

and readers. His ability to get his point of view across in complicated scientific disputes without resorting to the argument “because I say so” is another rare talent of his. The book “The Siberian Tatars. From the Spiritual Cultural Treasury” also includes articles on cultural and spiritual values and esthetic features of dastans, munadgats, and bayts. Without taking up a lot of space in this already extensive anthology, they provide substantial information to the reader.

The majority of lyric-epic pieces in the book are represented by dastans. The first to gather them was V. V. Radlov, who later included 16 dastans of the Tyumen, Tara, Tobolsk, and Baraba Tatars in his famous “Folklore Examples…” collection [Radlov, 1872]. At the same time, the scholar pointed out the similarity of these Siberian Tatar dastans with lyric-epic pieces of many other Turkic peoples. In the second half of the 20th century the Tatar folklorists Kh. Yarmi, F. Ahmatova, F. Urmancheev, Kh. Gatina, L. Zhamaletdinov, N. Ibragimov, Kh. Makmutov and others organized an expedition following the tracks of the great scholar and discovered that many dastans gathered in the 19th century were gone. F. Yu. Yusupov was also able to record only a part of the disappearing dastans. Nonetheless, these fragments are still of great academic importance.

Speaking of dastans, the author emphasizes that it is among the Siberian Tatars that they are mostly widespread and preserved. Whereas in Kazan and other regions along the Volga river, orally improvised dastans disappeared earlier in time. The Kazan Tatars, known to be academically stronger than other Turkic peoples, were focused more on the development of written literature. Siberian Tatar folklore preserved the dastan genre to the present days, although not to the full extent. According to F. Yu. Yusupov, this fact can be explained by the severalty of the Siberian Tatars who live their ordinary lives in the marshy lands among lakes and rivers away from high roads, not really being influenced by others. The author considers the epic folklore pieces of the Siberian Tatars to be a genre and draws attention to their crucial characteristics, based on the point of view of scholars who focused on analyzing dastans (V. V. Radlov, F. V. Akhmatova, M. I. Akhmetzyanov, M. Kh. Bakirov et al.).For instance, along with the Islamic traditions, dastans also cover mundane customs and traditions.

Certain information on folklore pieces of various genres is also given at the end of the book in the section entitled “Notes”. It provides the data on when and by whom the folklore masterpieces, included in the anthology, were recorded, the authors of Russian translations and published sources. It is impossible not to mention a statement left in this section about the dastan called “Karaca”. This piece of folklore, recorded by V. V. Radlov in the village of Sala, tells a story of a person named Karaca, a historical figure who fought alongside Kuchum Khan in many battles against Russians. A. V. Prelovsky, who translated “Karaca” to Russian and compiled a collection book with F. V. Akmatova, wrote that the name of this prominent figure was often mentioned in Russian chronicles. Most importantly, the plot of this dastan has a connection to ancient Turkic Yenisei gravestone inscriptions, dating back to the 8th century, studied and decoded many centuries later by V. V. Radlov. The scholar points out the amazing similarity of the depiction of Karaca’s sorrow after his son’s death in war to the mourning of Bilge Kagan over the loss of his younger brother Kulgatin in “The Notes Dedicated to Heroes”, and, regardless of the almost a thousand year gap between these two pieces, their similarities in structure and the ability to describe these raw and powerful emotions. “How strong the people’s memory has to be in order to preserve ancient poems word by word! – Poetry is indeed timeless!” [see Yusupov, 2014, p. 43], as said by Anatoly Prelovsky. Such interesting facts, included in the book by F. Yu. Yusupov, allow readers with different levels of education and erudition to have a better understanding of the folklore monuments.

Unlike dastans, munadgats and bayts are a lot more common and can be found in any area populated by Tatars. The fact that pieces of these genres are still being created and actively used shows their true ethnic nature, national spirit and soul of the Tatar people. When it comes to these genres created by the Siberian Tatars, F. Yu. Yusupov bases his analyses on the works of the prominent Tatar scholars M. Kh. Bakirov and A. Kh. Sadekova, who compiled and published a collection of munadgats, and F. V. Akhmatova, who specializes in compilation and study of bayts. Notably, every munadgat and every bayt (with the exception of a couple of them) given in the book was recorded during the expeditions led by F. Yu. Yusupov himself, transcribed personally by him and translated into Russian with his participation. The scholar’s analysis shows that the munadgats and bayts of the Siberian Tatars go in sync with folklore pieces in other regions. For instance, such examples as “Khan mächetpäyet”, portraying the fall of the Ka-

zan Khanate as a great tragedy, shows that different ethnic groups of the Tatar nation share the same history and are united in our spiritual culture. To sum up, this book contains folklore masterpieces created by people, who changed them when passing them over from person to person. Created many centuries ago and nowadays, they vividly narrate about our people's lifestyles, emotions, and feelings thus making them a reliable material for research in the cultural history of our nation in different areas.

**References**

Radlov, V.V. (1872). *Narechiya tyurkskih plemen, zhivuschih v Yuzhnoy Sibirii Dzhungarskoi stepi.I otdelenie* [Dialects of the Turkic Tribes Living in South Siberia and the Dzungarian Steppe. Part I]. Obraztsy narodnoi literatury I tiurkskih plemen, zhivuschih v Iuzhnoi Sibiri I Dzhungarskoi stepi, sobranyi V. V. Radlovyim. Chast IV. Narechia barabintsev, tarskih, tobolskih i tiumenskih tatar. 411 p. Saint Petersburg. (In Russian)

Radlov, V.V. (2012). *Obraztsy narodnoi literatury I tyurkskih plemen, zhivuschih v Yuzhnoy Sibirii Dzhungarskoy stepi* [Samples of Folk Literature of the Turkic Tribes Living in Southern Siberia and the Dzungarian Steppe].Chast IV. Narechiya barabintsev, tarskih, tobolskih I tyumenskih tatar / Sost. F.Yu.Yusupov.519 p. Kazan: Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

Yusupov, F. (2014).*Sibirskie tatary. Iz sokrovischnitsy i duhovnoi kultury .Antologia folklora sibirskih tatar: dastany, munadzhaty, baity* [The Siberian Tatars. From the Spiritual Cultural Treasury. Anthology of the Siberian Tatars' Folklore: Dastans, Munadgats, Bayts]. 648 p. Kazan: Izd-vo Kazanskogoun-ta. (In Russian)

Zakirova, L.N. (2013). *Vasilii Vasilevich Radlov: kazanskiy period deiatelnosti: Monografia* [Vasily Vasilyevich Radlov: the Kazan Period of His Activity: A Monograph]. 292 p. Kazan: Ihlas. (In Russian)

---

# Ф.Й.ЙОСЫПОВНЫҢ «СИБИРСКИЕ ТАТАРЫ. ИЗ СОКРОВИЩНИЦЫ ДУХОВНОЙ КУЛЬТУРЫ. АНТОЛОГИЯ ФОЛЬКЛОРА СИБИРСКИХ ТАТАР: ДАСТАНЫ, МУНАДЖАТЫ, БАИТЫ. КАЗАНЬ: ИЗД-ВО КАЗАНСКОГО УН-ТА, 2014. 648 С.» КИТАБЫНА БӘЯЛӘМӘ

**Фәнзилә Хәким кызы Җәүһәрова,**
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге,
Россия, 420015, Казан ш., Пушкин ур. , 66/33 нче йорт,
zavgarova@inbox.ru.

**Гафур Мәсгут улы Сөнгатов,**
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге,
Россия, 420015, Казан ш., Пушкин ур. , 66/33 нче йорт,
gsungatov@mail.ru.

Филология фәннәре докторы, профессор, Төркия лингвистик җәмгыятенең мөхбир-әгъзасы Ф. Й. Йосыповның «Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Антология фольклора сибирских татар: дастаны, мунаджаты, баиты. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 2014. 648 с». китабында XIX гасырдан алып XXI гасырга кадәр чорда язып алынган дастаннар, мөнәҗәтләр һәм бәетләр тупланган. Бөек тикшеренүче-галим В. В. Радлов традицияләрен дәвам итеп, автор халык авыз иҗаты әсәрләрен әйтелешне тулы чагылдырган транскрипциядә бирә.

Мөнәҗәт һәм бәетләрне үзе язып алган Ф. Й. Йосыпов аларның татар халкының башка этник төркемнәрендәге фольклор әсәрләре белән аваздаш булуын, ә дастаннарның себер татарларында гына сакланып калып, башка төрки халыклардагы шул жанр әсәрләре белән охшаш булуын билгели. Ядкәрләрнең рус теленә юлга-юл тәрҗемә ителүе, себер татарлары һәм һәр жанрның үзенчәлекләре турында мәгълүматлар китерелү китапны укучылар аудиториясе шактый зур булачагын күрсәтә.

**Төп төшенчәләр:** халык авыз иҗаты, рухи мәдәният ядкәрләре, әсәр тексты, дастаннар, мөнәҗәтләр, бәетләр.

Кешелек җәмгыяте алган киткән саен, халыкларның рухи-мәдәни кыйммәтләренә игътибар артканнан арта бара. Халык авыз иҗатын, үз милләтенең борынгырак чорларга караган тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнү Европа дәүләтләрендә мәдәният белән идарә итә торган оешмаларның иң әһәмитле юнәлеше булып санала. Мөмкин булганнарын яңадан тормышка кайтару кебек проектлар бу тармакларга караган иң әһәмиятле мәсьәләләр рәтенә куела, чөнки европа халыкларының рухи мәдәнияте тулысы белән юкка чыгу куркынычы фараз кылуларны узып, аяныч чынбарлыкка әйләнде. Бу күзлектән караганда, безнең хәлебез дә европа халыкларына якынлаша: татарларда бүгенге көндә халык авыз иҗатының күп кенә жанрлары бөтенләй югалып бара. Иминлегебезне, мөстәкыйльлегебезне саклауда зур каһарманлыклар күрсәткән батырларыбыз, тарихи шәхесләребез тасвирланган яки ике яшь йөрәкнең кайнар, саф мәхәббәте белән сокландырган дастаннарыбызны йөзләгән кешегә төннәр буе сөйләп чыгучы чәчәннәребезне тарих давыллары алып китте инде. Яшәеш рәвешебезне тамырдан үзгәрткән, рухи мәдәниятебезне загыйфьләндергән бу хәлләрне берничә нәсел сизми дә калды. Әле моннан берике гасыр элек кенә күпләрне сокландырган, шаккатырган рухи байлыгыбыз, иске әйберләр кебек чүплеккә ташланып, таралып, югалып бетәр дип аксакалларыбыз башларына да китереп карамаганнардыр.

Әлеге аяныч язмышны үз башларыннан кичергән европа галимнәре Россия империясендә рухи мәдәният ягыннан иң бай булган төрки кавемнәрнең дә шул хәлдә калачакларын алдан ук белеп эш иткәннәр, рухи мәдәният үрнәкләрен көчләре җиткән кадәр киләчәк буыннарга да саклап калу юлына керешкәннәр. Шундый асыл затларның берсе – Вильгельм Фридрихович (Василий Васильевич) Радлов. В. В. Радлов 1837 елда Германиядә Берлин шәһәрендә туа, яшьтән үк бик тырыш һәм сәләтле була. 1854 елны гимназияне уңышлы тәмамлап, Берлин университетының фәлсәфә факультетына укырга керә. Ул вакытларда мондый факультетларда тел, тарих, антропология фәннәре дә укытыла торган була. Төрле телләрнең килеп чыгышларына багышланган хезмәтләре белән дан тоткан, телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнү фәненә нигез салучы мәшһүр Август Поттның лекцияләрен йотлыгып тыңлау Фридрихка гомерлек шөгылен сайлап алырга этәргеч була. Шулай да аның нәкъ көнчыгыш телләр белгече булып китеп, урал-алтай теориясен үстерүгә гаять зур өлеш кертүенә В. Шотт белән якын мөнәсәбәтләрдә булуы сәбәп була. Остазларының тел белеменең сихри сәхифәләре турында сөйләгәннәре яшь егетне бөтен тормышын Россиянең Азия өлешендә яшәгән төрки халыклар, беренче чиратта, себер татарларының теле, тарихы белән бәйләргә дигән карарга килергә ярдәм итә. 1858 елны В. В. Радлов, ул вакытта дөньяның иң атаклы Берлин университетын тәмамлаганнан соң, мәшһүр остазы В. Шоттның Россиядәге атаклы төрек телләр белгече О. Бётлингка шәкерте Фридрихка ярдәм итүен сорап язган хатын алып, мең бәлаләр белән, Санкт-Петербургка килеп җитә. Аның иң зур хыялы Көнбатыш Себердә яшәүче, моңа кадәр гыйльми яктан беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән татарлар янына барып җитү, аларның тарихы, теле, гореф-гадәтләре турында фәнни-тикшеренү эшләрен башлап җибәрү була. Ул вакытта ук инде рус хөкүмәтенең бу якларга чит ил кешеләрен кертмәскә тырышуы сәбәпле, тормыштагы иң бөек хыялын тормышка ашыру өчен, булачак галим, Германия ватандашлыгыннан баш тартып, Россия паспортын алырга мәҗбүр була. Шул минуттан Фридрих Вильгельм рус кешесенә әйләнеп, Василий Васильевич булып китә. Яшь егетнең мондый тәвәккәллеген рус җәмәгатьчеге гаҗәпләнеп, тетрәнеп кабул итә. Бу хәлләрдән соң, өч көн дә үтми, яшь галимгә Себергә юл ачыла һәм Европаның җылы табигатенә нисбәтле җиңелчә генә киенгән Василий, атлы чанага утырып, Барнаулга юл тота.

В. В. Радлов кышларын Барнаулның һөнәр училищесында (хәзерге политехника институты тибындагы югары уку йорты) алман, латин телләрен укыту белән шөгыльләнсә, җәйләрен татар һәм башка төрки халыклар яши торган төбәкләргә фәнни экспедицияләр оештыра. Аларда тупланган материаллар нигезендә В. В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. Часть IV. Наречие барабинцев, Тарских, Тобольских и Тюменских татар» (Санкт-Петербург, 1872) китабы дөнья күрә [Радлов, 1972]. Әлеге хезмәт белән Россия тюркология мәктәбе, аерым алганда, татар фольклористика фәне башланып китә дип исәпләнә. Китапка себер татарларының әкиятләре, 680 юлдан торган 29 җыры, риваятьләре

һәм дастаннары – барлыгы 121 әсәр кертелгән. Галимнең тууына 175 ел тулу уңаеннан, бу күләмле хезмәтне 2012 елда Казан федераль университеты профессоры Ф. Й. Йосыпов Казанда бастырып чыгарды [Радлов, 2012].

Кызганычка каршы, В. В. Радловның әлеге китабыннан соң, аның принципларына нигезләнеп эшләнгән, ягъни себер татарларының халык әдәбияты әсәрләре җирле сөйләмдәгечә язып алынып, транскрипциядә бирелгән хезмәтләр дөнья күрмәде. Тюрколог адресына бер мәкаләдән икенчесенә күчеп йөргән 1-2 җөмләдән торган мәдхиядән башка, аның олы хезмәтенә дә лаек бәя бирелмәде, нинди бөек эш башкарганлыгын ачып салган бер генә мәкалә дә басылып чыкмады. Ниһаять, соңгы елларда бу өлкәдә алга китеш сизелде: Казан федераль университеты профессоры Ф. Й. Йосыпов галимнең тормышы һәм фәнни иҗаты буенча дистәдән артык фәнни мәкалә бастырып чыгарды, чит илләрдә һәм Россиядә үткәрелгән халыкара симпозиумнарда чыгышлар ясады. *Шулай ук Л.Закирова тарафыннан В. В. Радловның Казан чоры эшчәнлеге системалы һәм комплекслы яктыртылган монография дә игътибарга лаек [Закирова, 2013].*

Соңгы елларда, халыкларның аралашуы активлашу, аерым илләргә, төбәкләргә генә хас үзенчәлекләрнең җуела бару дәверендә, аларның рухи кыйммәтләрен барлау, өйрәнү, элекке йолаларын, гореф-гадәтләрен, ышануларын, идеаларын ачыклау һәм аларга чагыштырып бәя бирү ихтыяҗы тагы да арта. Татар һәм башка төрки халыклар галимнәре-тикшерүчеләре бу юнәлештә шактый эш башкара. Филология фәннәре докторы, профессор, Төрек лингвистик җәмгыятенең мөхбир-әгъзасы Ф. Й. Йосыпов тарафыннан төзелеп бастырылган «Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Антология фольклора сибирских татар: дастаны, мунаджаты, баиты» исемле китап – шундый зарури һәм мөһим эшләрнең берсе [Юсупов, 2014].

Ф. Й. Йосыпов себер татарлары телен, гореф-гадәтләрен өйрәнүгә илле елдан артык гомерен багышлый. Сакланган ядкәрләрне эзләп табуга тәҗрибәле галимнең үз фикере бар. Билгеле бер төбәккә экспедиция белән барганда, ул материал җыйнауга комплекслы якын килү бурычын куеп эш итә. Әйтик, тел үзенчәлекләрен өйрәнгәндә, төбәк тарихына караган хикәят-риваятьләр дә, һәртөрле фольклор әсәрләре дә, этнографик мәгълүматлар да язып алына. Без сүз алып бара торган китап та галимнең гомер буена максатчан һәм җентекле эшләвенең, рухи ядкәрләребезне туплау юлында фидаи хезмәт итүенең җимеше булып тора. «Халыкта инде җыйнарлык әйберләр калмаган, булганнарын күптән язып алганнар, хәзергеләр берни белми» диючеләргә Ф. Й. Йосыпов туплаган һәм әлеге китапка кертелгән материалларның теркәлү вакытына игътибар итәсе иде: мөнәҗәт һәм бәетләрнең бер өлеше – XX гасырның 80 елларында, тагын бер өлеше 2010 елларда язып алынган. Димәк, күп кенә төбәкләрдә әле буыннар чылбыры өзелеп бетмәгән, ул аерым фидакарьләрнең ихлас тырышлыгы, әби-бабалары мирасына булган мәхәббәте белән һаман яңартылып тора.

Хезмәтнең исеменнән күренгәчә, ул себер татарлары халык авыз иҗатындагы лиро-эпик жанрларга багышланган. Болар – дастаннар, мөнәҗәтләр, бәетләр. Эчтәлеген һәм төзелешен карауга ук, китап концепциясенең дөнья һәм төрки тел белеме казанышларын исәпкә алып һәм күпьеллык тәҗрибәгә таянып, яңача фәнни нигезгә корылган булуы турында фикер туа. Иң беренче шуны искәртү мөһим: бу хезмәт – себер татарларының халык әдәбияты әсәрләре туплап бирелгән беренче антология. Ул моңа кадәр бу өлкәдәге бушлыкны тутыруга зур адым ясавы белән дә үзенчәлекле, чөнки татар халкын оештыручы төп өч этносның – казан татарларының, мишәрләрнең һәм себер татарларының халык авыз иҗаты тупланган аерым антологияләре юк иде. Фольклор текстларының, В. В. Радлов хезмәтендәгечә үк, себер татарлары сөйләмендәгечә транскрипциядә бирелүе – китапның тагын бер зур әһәмиятле ягы. Бу себер татарларының рухи мәдәниятен саклап калуда мөһим чараларның берсе булып тора. Мондый алым, һичшиксез, алга таба нәшер ителәчәк хезмәтләрнең дә нигезендә ятарга тиеш. Төрки фольклористика буенча шөгыльләнә торган күп кенә галимнәр фольклор текстларын татар әдәби теленә тәрҗемә итеп итеп бирүне бик гаҗәпләнеп кабул итәләр иде. Автор В. В. Радлов, Н. Ф. Катанов, Д. Г. Тумашева, Л. В. Дмитриева һ.б. шундый күренекле тюркологлар кулланган һәм хәзерге заман галимнәренә яхшы таныш булган рус академик транскрипциясеннән файдалана. Галимнәр арасында киң таралган транскрипцияне куллану текстларны укуны шактый җиңеләйтә. Мондый фәнни ысул халык авыз иҗаты әсәрләрен язып алынган вариантындагыча укырга, һәр сүзнең аһәңен билгеле бер

сөйләштәге яңгырашын тоярга мөмкинлек бирә. Текстлар, юлга-юл тәрҗемә итеп бирелүләренә карамастан, рус телендә дә матур яңгырыйлар. Моңа, һичшиксез, авторның себер татарлары диалектын яхшы белүе ярдәм иткән.

Китапның шактый өлеше себер татарларының килеп чыгышын, формалашу тарихын яктыртуга багышланган. Себер татарларын автор татар халкы оешуда катнашкан өч төп этник төркемнең берсе буларак карый һәм аларның Көнбатыш Себер киңлекләрендә б.э. кадәр үк яшәгән борынгы төрки кабиләләргә барып тоташуын, I меңъеллыкта дәвамлы рәвештә килеп торган сөннәр, кыпчаклар һ.б. белән катнашканлыкларын ассызыклый. Моннан тыш, себер татарлары Идел-Урал буйларыннан күчкән болгарлар, күрше башкорт, казакъ, нугай ырулары белән дә гасырлар дәвамында тыгыз аралашкан. Аларның формалашуында төрле чорда, бигрәк тә Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, көнчыгышка таба күчә барган казан татарларының да роле зур булган. Ф. Й. Йосыпов Идел-Урал якларыннан килгән казан татарларының яңа авыллар нигезләве яки себер татарлары авылларында яшәп китүләре турында яза. Әлбәттә, аларның тиз катнашып, бердәй булып китүләренә бер телдә сөйләшүләре генә түгел, дин уртаклыгы да сәбәп булган. Ислам дине исә, Ф. Й. Йосыпов китабында күрсәтелгәнчә, болгарлар аркылы ук керә башлый. Моннан тыш, Себер ханнары соравы буенча Урта Азиядән махсус китертелгән ислам миссионерларының да эшчәнлеге зур була. Галим әлеге мәгълүматларны күпсанлы тарихи-этнографик, мәдәни чыганакларга таянып китерә. Борынгыдан бер-берсенә якын кардәш ыруг-кабиләләрдән булган татарлар тубыл-иртыш җирлегендә мөстәкыйль рәвештә үз дәүләтчелекләрен булдыра алганнар. Рус дәүләте тарафыннан басылып алынганнан соң, гасырлар буена милли һәм дини изелүгә дучар ителгәннәр. Идел буе татарларыннан ерак яшәү, татар әдәби теленең тәэсире азаю да (XX гасырның 60 елларыннан татарча укыту туктатыла), себер татарларының бик киң таралып урнашуы да – әлеге кардәшләребезнең милли-мәдәни үсешен тоткарлаган факторлар. Югыйсә, автор билгеләгәнчә, идел буе татарларындагы кебек үк, себер татарларында да терлекчелек һәм игенчелек эшләре алга киткән була, алар хәтта металл җитештерү белән дә шөгыльләнгәннәр.

Китаптагы «Себер татарлары» исемле кереш мәкаләнең тексты киң катлау укучыга аңлаешлы, фәнни-популяр стильгә якын тел белән язылган, ул тар даирәдә генә кулланылучы пассив терминнардан азат. Бу факт әлеге зур күләмле китапның фән белән шөгыльләнүчеләргә генә түгел, мәдәният, мәгариф, мәгълүмат чаралары тармакларында эшләүчеләргә, гомумән, халыкның рухи мирасы белән кызыксынучыларның барысына да атап төзелгәнлеген күрсәтә. Әлеге җыентыкта себер татарлары диалектларының төп фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре турында да мәгълүмат бар. Ф. Й. Йосыпов – башка татар сөйләшләре белән беррәттән, себер татарлары диалектларының төп фонетик үзенчәлекләрен яктырткан, морфологик системасын барлап, аны диалект теле яссылыгында анализлаган галим. Автор себер татарлары яшәгән бар өлкәләргә таралган сөйләмнең татар теленең урта һәм көнбатыш диалектларыннан аера торган төп классификацион билгеләрен күрсәтә. Биредә себер диалектларының урта диалект белән охшаш булып, мишәр диалектына каршы куела торган һәм мишәр диалекты белән бердәй үзенчәлекләренең урта диалектка каршы куела торган уртак яклары булуы турында да искәртелә. Мәсәлән, себер татарлары диалектларының фонетик системасы **й**-ләштерү, **ц**-лаштыру һәм **ч** авазын шартлаулы итеп әйтү, **а** сузыгының ачыграк әйтелеше ягыннан мишәр диалекты белән охшаш һәм бу күренеш аларны урта диалекттан аерып тора; калын **ķ, ғ** авазлары булу, ирен гармониясе тулы чагылу кебек классификацион билгеләре белән урта һәм көнчыгыш диалектлар көнбатыш диалектка каршы куела һ. б.

Бу урында бөтен гомерен татар халкының телен, рухи ядкәрләрен өйрәнүгә, шул белемне яшь буынга җиткерүгә багышлаган Фәрит ага Йосыповның язу һәм сөйләү рәвешенә аерым тукталып китү урынлы булыр иде. Фәнни конференциядә чыгыш ясыймы ул, лекция сөйлиме, теге яки бу мәсьәлә буенча утырышта берәр фикер әйтәме яки фәнни хезмәт язамы – барысы да тыңлаучыга һәм укучыга аңлаешлы тел чаралары белән тәгъбир ителә. Катлаулы фәнни бәхәсләрдә дә үз фикереңне төгәл һәм дәлилле итеп, «мин беләмлек»тән башка гына җиткерә алу, һичшиксез, бик күпләр ирешә алмый торган биеклек. «Себер татарлары. Рухи мәдәният хәзинәләреннән» исемле китапта дастаннар, мөнәҗәтләр һәм бәетләрнең мәдәни-рухи кыйммәте, идея-эстетик үзенчәлекләре хакындагы мәкаләләр дә, болай да зур күләмле антологиянең күп урынын алмыйча, җыйнак

кына китереләләр, әмма укучыга бай мәгълүмат бирәләр.

Китапта урын алган лиро-эпик әсәрләрнең зур күпчелеген дастаннар тәшкил итә. Заманында аларны беренче булып В. В. Радлов язып кала алган һәм үзенең мәшһүр «Халык әдәбияты үрнәкләре...»нә түмән, тара, тубыл, бараба татарларыннан теркәлгән 16 дастан керткән [Радлов, 1872]. Шул вакытта ук галим себер татарларында таралган дастаннарның күп төрки халыкларда сакланган шундый ук лиро-эпик әсәрләр белән охшаш булуын әйткән. XX гасырның икенче яртысында татар фольклорчылары Х. Ярми, Ф. Әхмәтова, Ф. Урманчеев, Х. Гатина, Л. Җамалетдинов, Н. Ибраһимов, Х. Мәхмүтовлар бөек галимнең эзләре буйлап экспедицияләр оештыралар һәм ул XIX йөздә дастаннар язып алган авылларда аларның күбесенең инде сакланмаганын күрәләр. Ф. Й. Йосыповка да югалып баручы дастаннарның аерым өлешләрен генә язып алырга мөмкин була, шулай да бу өзекләр дә фән өчен гаять әһәмиятле материал булып торалар.

Дастаннар турында сүз алып барганда, автор-төзүче аларның нәкъ менә себер татарларында күбрәк таралуын һәм саклануын искәртә. Казан һәм башка Идел буе төбәкләрендә исә телдән көйләнүче дастаннар элегрәк юкка чыкканнар. Казан татарлары, төрки халыклар арасында гыйлемлерәк булып, язма мәдәниятне үстерүгә йөз тотканнар. Себер татарлары фольклоры дастан жанрының, аз күләмдә булса да, соңгы дәвергә кадәр сакланып килүе белән үзенчәлекле. Ф. Й. Йосыпов фикереннән аңлашылганча, моңа себер татарларының олы юллардан читтә, сазлыклы урыннарда, күлләр-елгалар арасында яшәп, үзләренең гадәти тормыш рәвешләрен дәвам иттерүләре, башкалар йогынтысын аз тоюлары сәбәп булган. Автор, дастаннарны максатчан тикшергән галимнәр фикеренә таянып (В. В. Радлов, Ф. В. Әхмәтова, М. И. Әхмәтҗанов, М. Х. Бакиров һ.б.), себер татарларыннан язып алынган эпик әсәрләргә жанр буларак күзәтү ясый, материалның әһәмиятле якларына игътибарны юнәлтә. Әйтик, дастаннарда ислам традицияләре белән бергә, җирле гореф-гадәтләр, йолалар да чагылыш тапкан.

Төрле жанрларга караган әсәрләр турында мәгълүмат бирү китапның азагында урнашкан «Искәрмәләр» бүлегендә дә дәвам итә. Биредә антологиягә кертелгән халык җәүһәрләренең кайчан һәм кем тарафыннан язып алынулары, русчага тәрҗемә авторлары һәм басылганнарының чыганаклары күрсәтелгән. Шунда «Караца» дастанына карата әйтелгән бер фикергә аерым тукталып китмичә мөмкин түгел. В. В. Радлов Сала исемле авылда язып алган әлеге әсәр герое Карача тарихи шәхес була, ул Күчем хан янәшәсендә русларга каршы күп яуларда катнаша. «Караца»ны русчага тәрҗемә итеп, Ф. В. Әхмәтова белән төзегән җыентык авторы булган А. В. Преловский бу олы шәхеснең рус елъязмаларында еш телгә алынуы турында яза. Иң әһәмиятлесе – дастанның сюжет тамырлары VIII йөзгә караган, күп гасырлар үткәч, В. В. Радлов тарафыннан өйрәнелгән һәм укылган борынгы төрки енисей каберташ язмаларына барып тоташуын күрсәтү. Галим, ике яшь сугышчы улы үтерелгәннән соң, Карачаның хәсрәтен сурәтләү «Геройларга багышланган язмалар»да Билге каганның энесе Күлтәгин үтерелгәч елавын тасвирлауга бик охшаганлыгын әйтә, әлеге ике әсәрне мең елга якын вакыт аерып торса да, аларның төзелешләре һәм кайгы-хәсрәт көчен, тирәнлеген чагылдырулары ягыннан бик якын булуларына гаҗәпләнә. «Борынгы шигырьләрне сүзгә-сүз саклау өчен халык хәтеренең никадәр көчле һәм ныклы булуы кирәк! – Чыннан да, поэзия мәңгелек!» [бу хакта кара: Юсупов, 2014, б. 43] – дип белдерә Анатолий Преловский. Ф. Й. Йосыповның шушындый кызыклы мәгълүматларны китапка кертүе белем һәм эрудиция ягыннан төрле дәрәҗәдә торган укучыларга халык иҗаты ядкәрләрен тулырак аңларга ярдәм итә.

Дастаннардан аермалы буларак, мөнәҗәтләрнең һәм бәетләрнең таралышы бик киң. Алар татар халкы яши торган һәр төбәккә хас. Әлеге жанрларга караган әсәрләрнең һаман да иҗат ителүе һәм актив кулланылышка ия булулары аларның чын мәгънәсендә миллилеген, халыкчанлыгын, татар кешесенең җан авазын чагылдыруын күрсәтә. Себер татарларыннан тупланган бу жанрлар турында сүз алып барганда, аларга бәя бирүдә һәм төркемләүдә Ф. Й. Йосыпов фольклор өлкәсендә зур эшчәнлеге белән танылган күренекле татар галиме М. Х. Бакиров, мөнәҗәтләрне туплап дөньяга чыгарган А. Х. Садекова, бәетләрне җыйнау һәм өйрәнү белән шөгыльләнгән Ф. В. Әхмәтова хезмәтләренә дә таяна. Шунысы игътибарга лаек: китапта китерелгән һәр мөнәҗәт һәм бәетләрнең (бер-икесеннән кала) барысы да Ф. Й. Йосыпов җитәкчелек иткән экспедицияләрдә язып алынган, үзе тарафыннан траскрипцияләнгән һәм аның катнашында

рус теленә тәрҗемә ителгән. Галим ясаган анализдан себер татарлары мөнәҗәтләренең һәм бәетләренең халкыбызның башка төбәкләрдә таралган әсәрләре белән аваздаш икәнлеге күренә. Мәсәлән, Казан ханлыгының җимерелүе афәт буларак сурәтләнгән «Хан мәчет пәйет» кебек мисаллар татар милләтенең төрле этник төркемнәренең уртак тарихи язмышлы булуларын күрсәтә, рухи мәдәниятебезнең бер икәнлеген тагын да ныграк аңларга ярдәм итә. Йомгаклап әйткәндә, моннан йөзләрчә ел элек тә, хәзер дә халык аңын, күңелен чагылдырган, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, эчке кичерешләрен образлы сурәтләгән һәм кешеләрнең үз авызыннан көйләнгән җәүһәрләрнең китап булып дөнья күрүе халкыбызның мәдәният тарихын төрле юнәлешләрдә чагыштырып тикшерүгә бай, ышанычлы материаллар бирә.

**Әдәбият**

*Закирова Л.Н.* Василий Васильевич Радлов: казанский период деятельности: Монография. Казань: Ихлас, 2013. 292 с.

*Радлов В.В.* Наречия тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. I отделение. Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи, собраны В.В.Радловым. Часть IY. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. 411 с.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар / Сост. Ф.Ю.Юсупов. Казань: Татар.кн.изд-во, 2012. 519 с.

*Юсупов Ф.* Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Антология фольклора сибирских татар: дастаны, мунаджаты, баиты. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 2014. 648 с.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА КНИГУ Ф. Ю. ЮСУПОВА «СИБИРСКИЕ ТАТАРЫ. ИЗ СОКРОВИЩНИЦЫ ДУХОВНОЙ КУЛЬТУРЫ. АНТОЛОГИЯ ФОЛЬКЛОРА СИБИРСКИХ ТАТАР: ДАСТАНЫ, МУНАДЖАТЫ, БАИТЫ. КАЗАНЬ: ИЗД-ВО КАЗАНСКОГО УН-ТА, 2014. 648 С.»

**Фанзиля Хакимовна Завгарова,**
ГБУ «Республиканский центр развития традиционной культуры»,
Россия, 420015, Казань, ул. Пушкина, д. 66/33,
zavgarova@inbox.ru.

**Гафур Масгутович Сунгатов,**
ГБУ «Республиканский центр развития традиционной культуры»,
Россия, 420015, Казань, ул. Пушкина, д. 66/33,
gsungatov@mail.ru.

В книгу доктора филологических наук, профессора, члена-корреспондента Лингвистического общества Турции Ф. Ю. Юсупова «Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Антология фольклора сибирских татар: дастаны, мунаджаты, баиты» включены дастаны, мунаджаты и баиты, которые были записаны в XIX–XX вв. Продолжая традиции великого исследователя-ученого В. В. Радлова, произведения устного народного творчества автор приводит в транскрипции, достоверно отражающей местное произношение.

Говоря о мунаджатах и баитах, которые записывал сам автор, Ф. Ю. Юсупов отмечает их созвучность с фольклорными произведениями других этнических групп татарского народа, а дастаны, которые сохранились только у сибирских татар, схожи с произведениями такого жанра других тюркских народов. В книге приводятся данные о том, что по содержанию и форме эти дастаны восходят к древнетюркским орхоно-енисейским письменным памятникам. Построчный перевод этих литературных жемчужин на русский язык, научная информация об истории сибирских татар и особенностях каждого жанра позволяют думать, что читательская аудитория книги будет весьма широкой.

**Ключевые слова:** устное народное творчество, памятники духовной культуры, фольклорный текст, дастаны, мунаджаты, баиты.